Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Ямбакты авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАР

28 апрель 2021 ел №16

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге башкарма комитетының «2020 елда Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында»2020 елның 1 апрелендәге 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $174^3$ статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләр турында» 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге башкарма комитетының «2020 елда Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 1 апрелендәге 8 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар исемендә «2020 елда» сүзен төшереп калдырырга.

1.2. Каррга кушымта атамасында «2020 елда» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Ямбакты авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Э. Галәветдинов.